**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮТАЗЫ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**423962, Ютазы авылы,**
**Дмитров урамы, 2**
**тел. 4-00-91**
**факс: 8 (85593) 4-00-93**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЮТАЗИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**423962 с. Ютаза,**
**ул. Дмитрова, д.2**
**тел. 4-00-91**
**факс: 8 (85593) 4-00-93**

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№4** **«08» февраль 2018 ел**

**Сайлау участоклары территориясендә басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү һәм җиһазлау турында**

«Россия Федерациясе Президентын сайлау турында» Федераль законның 55 маддәсендәге 7 пункты нигезендә, Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Россия Федерациясе Президентын сайлау буенча басма агитация материаллары урнаштыру өчен сайлау участогы территориясендә махсус урыннар билгеләргә.

2. Махсус урыннар бүлеп биргәндә түбәндәгеләрне каларга:

- сайлаучыларны урнаштыру һәм урнаштырылган мәгълүмат белән таныштыру өчен уңайлы;
- теркәлгән кандидатларның басма агитация материалларын урнаштыру өчен тигез һәм җитәрлек мәйдан;
- сайлау комиссияләренең мәгълүмати материалларын урнаштыру өчен җитәрлек мәйдан;

3.объектларда махсус урыннар урнаштыру шартлары турындагы мәсьәләне аларның хуҗалары белән килештерергә;

4.басма агитация материалларын урнаштыру өчен бүлеп бирелгән урыннарны һәм алар янәшәсендәге территорияләрне санитар тәртиптә тотуны тәэмин итәргә.

5.Ютазы муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенә басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар урнаштыру урыны турында мәгълүмат бирергә.

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырылган: www.yutaza.tatar.ruhttp://pravo.tatarstan.ruhttp://www.yutaza.tatar.ru

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Ютазы авыл җирлеге башлыгына йөкләнде.

Ютазы авыл җирлеге башлыгы: Г.Г.Сәфиуллина

Ютазы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2018 елның 08 февралендәге
4 санлы карарына 1 кушымта

**Россия Федерациясе Президентын сайлауга әзерлек һәм аны үткәрү чорында 2811 санлы Ютазы сайлау участогы территориясендә басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар исемлеге**

| Сайлау участогы саны | Агитация басма материалларын урнаштыру урыннары саны | Агитация басма материалларын урнаштыру урыннары адресы |
|---|---|---|
| №2811 | ***6*** | Ютазы авылы, Дмитров ур., 9 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стенды;<br>Ютазы авылы, Совет ур., (обелиск янында) урнашкан мәгълүмат стенды;<br>Ютазы авылы, Дмитров ур., 2 йорт адресы буенча урнашкан афиша тумбасы;<br>Ютазы авылы, Совет ур., 21А йорт адресы буенча урнашкан Ютазы кафесы;<br>Ютазы авылы, Вахитов ур., 16 йорт адресы буенча урнашкан “Азык-төлек” кибете;<br>Ютазы авылы, Комсомол ур., буенча урнашкан “Чатра” кибете”. |
| №2812 | ***3*** | Ык авылы, Яшел урам буенча урнашкан “Запас частьлар” кибете;<br>Ютазы авылы, Октябрь ур.,8 йорт адресы буенча урнашкан “Чибәр тау” кибете;<br>Ютазы авылы, Загот-Зерно урамы буенча урнашкан мәгълүмат стенды. |
| №2813 | ***2*** | Алма-Ата авылында урнашкан мәгълүмат стенды (“Вафауллин” КФХ офис бинасы);<br>Алма-Ата авылындагыЮтазы районы РайПо кибете. |